РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.09.2024 Буа шәһәре №254/Бк/к

2024 елның 1 сентябреннән «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Мирас» яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең «Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 15 августындагы 706 номерлы карары, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» РФ Законының 1992 елның 07 февралендәге 2300-1 номерлы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2014 елның 05 маендагы 316 номерлы «Түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында регламентлар раслау хакында», Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 16 маендагы 128/Бк/к номерлы карары белән Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 1 сентябреннән «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Мирас» яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны кушымта нигезендә расларга.
2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мирас» яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенә түләүле хезмәтләргә расланган тарифларны куллануны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.( http://buinsk.tatarstan.ru.)

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның яшьләр эшләре бүлеге башлыгы Р.Р. Зиатдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов

кушымта

2024 елның 1 сентябреннән «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мирас» яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтләр исеме | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) | Хезмәт берәмлеге |
|---|---|---|---|
| | **1. Уртак чаралар** | | |
| 1.1 | Актлар залында уртак чара | 500 | 1 чара |
| 1.2 | Тавыш, яктылык җиһазлары комплекты белән актлар залында уртак чара | 800 | 1 чара |
| 1.3 | 1 нче кат холлында уртак чара | 300 | бер сәгать |
| 1.4 | 1 нче кат холлында тавыш җиһазлары һәм телевизор комплекты белән уртак чара | 400 | бер сәгать |
| 1.5 | Кабинетларда уртак чара | 250 | бер сәгать |
| 1.6 | Гимнастика залында уртак чара | 250 | бер сәгать |
| 1.7 | Тавыш җайланмалары комплекты белән гимнастика залында уртак чара | 400 | бер сәгать |
| | **2. Мәдәни-массакүләм чаралар** | | |
| 2.1 | Мәдәни-агарту, ял итү, социаль характердагы чаралар оештыру һәм үткәрү һ. б. | 100 | 1 чара |
| 2.2 | Мастер-класслар оештыру һәм уздыру | 300 | 1 чара |
| 2.3 | Тематик квестлар, квизтлар оештыру һәм уздыру | 100 | 1 чара |
| 2.4 | Тематик очрашулар оештыру һәм уздыру | 100 | 1 чара |
| 2.5 | Конкурслар һәм фестивальләр оештыру һәм уздыру | 50 | 1 чара |
| 2.6 | Приставкада уеннар оештыру ( компьютерьда) | 200 | бер сәгать |
| 2.7 | Өстәл уеннарын оештыру | 100 | 1 чара |
| | **3. Хезмәт күрсәтүнең башка төрләре** | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.1 | Костюмнар биреп тору хезмәте | 500 | 1 көн |
| 3.2 | Тавыш яздыру хезмәте | 2000 | 1 җыр (композиция) |
| 3.3 | Фотостудия хезмәте | 700 | бер сәгать |